ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.05.2020 Олы Кайбыч ав. № 233

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи затлары исемлеген раслау турында» 2019 елның 17 декабрендәге 550 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 24 апрелендәге 17-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының « Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи затлары исемлеген раслау турында» 2019 елның 17 декабрендәге 550 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи затлары исемлеген Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.1 каралган (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органын, башка дәүләт органын, җирле үзидарә органын, предприятиене, учреждениене, башка оешманы үз исеме һәм вывескада урнаштырылырга тиешле мәгълүмат турында белешмәләр күрсәткәндә телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозуга карата), 2.4-2.8, 2.12-14.14, 2.15 статьясындагы 2 өлешендә, 2.16, 2.17, 3.2-3.8, 3.10 статьяларында (гражданнарга карата), 3.11, 3.14-17, 4.4, 5.1, 5.6 статьяларында (Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә

тормышка ашырыла торган муниципаль ташуларга карата) каралганча билгеләргә (Кушымта).»;

карар кушымтасына түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | |
|---|---|
| 2.17 статья. Яңа коронавирус инфекциясе (COVID-19) таралу нәтиҗәләрен булдырмауга һәм бетерүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәү | - «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ нең яшьләр сәясәте, физкультура һәм спорт бүлеге башлыгы; -«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ опека һәм попечительлек бүлегенең балигъ булмаганнар арасында гаилә иминсезлеге һәм хокук бозулар профилактикасы буенча баш белгеч-инспекторы |

---

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://kaybici.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Н.Макаров